ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 23 һәм 24 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 21 апрелендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 23 статьяда:
а) 4 өлешнең 4 пунктында «аеруча мөһим һәм катлаулы йөкләмәләрне үтәгән өчен премияләр» сүзләрен «премияләр, шул исәптән аеруча мөһим һәм катлаулы йөкләмәләрне үтәгән өчен» сүзләренә алмаштырырга;
б) түбәндәге эчтәлекле $8^1$ өлеш өстәргә:
«$8^1$. Әлеге Законда каралган дәүләт хезмәткәрләренә акчалата түләүне саклап калу һәм аларга акчалата компенсацияләр түләү очракларында дәүләт хезмәткәрләренә акчалата түләүне исәпләп чыгару Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип нигезләмәләрен исәпкә алган Татарстан Республикасы Президенты указында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

2) 24 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24 статья. **Дәүләт хезмәткәрләренә һәм дәүләт органы хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фонды**

1. Дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фонды һәм дәүләт хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү фонды дәүләт хезмәткәрләренә һәм дәүләт органы хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фондын тәшкил итә.

2. Дәүләт органнары дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фондларын булдырганда әлеге Законның 23 статьясындагы 2 һәм 4 өлешләрендә билгеләнгән түләүләрне башкару өчен акчалар карала.

3. Дәүләт органнары дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фондлары әлеге Законның 23 статьясындагы 2 һәм 4 өлешләрендә билгеләнгән түләүләрне финанс белән тәэмин итү өчен каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, шулай ук түбәндәгеләрне финанс белән тәэмин итү өчен, булдырыла:

1) күләме Татарстан Республикасы Президенты указы белән билгеләнә торган арттырылган акчалата түләүне аерым дәүләт органнарында түләүне;

2) федераль законнарда, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларында каралган башка түләүләрне.

4. Дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү әлеге Законның 23 статьясындагы 13 өлеше нигезендә башкарыла торган дәүләт органнарында дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фонды (фондның тиешле өлеше) дәүләт органы эшчәнлегенең эффективлыгы һәм нәтиҗәлелеге күрсәткечләре нигезендә булдырыла.

5. Әлеге Законның 23 статьясындагы 2 һәм 4 өлешләрендә билгеләнгән түләүләрне башкаруга җибәрелә торган акчалар суммасын билгеләү өчен вазыйфаи окладлар саны (бер елга исәпләгәндә) каралган дәүләт органнарының дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фондларын булдыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

6. Дәүләт хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү фондларын булдыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казан, Кремль
2022 ел, 29 апрель
№ 25-ТРЗ